Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № №XIX-6**

Балык Бистәсе штп. 2017 елның 29 мае

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын оештыру һәм алып бару тәртибе турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, “Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматка керү мөмкинлеген тәэмин итү хакында” 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр Советы Президиумының “Муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын алып бару турында”13.10.2016 ел, № ПР-26-4 карарын игътибарга алып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына таянып, норматив хокукый базаны камилләштерү, җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән норматив хокукый актларны исәпкә алуны унификацияләү һәм системалаштыру, аларның эшчәнлеге турында мәгълүматның ачыклыгын тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын оештыру һәм алып бару тәртибе турындагы Нигезләмәне расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын алып баруга вәкаләтле затлар итеп Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының тиешле җирле үзидарә органнары аппаратларының хокукый (юридик) бүлекчәләрен (юристларын) яисә норма чыгару (эшләү) эше өчен җаваплы затларны билгеләргә.

3. Әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән җирле үзидарә органнарына һәм аларның вәкаләтле бүлекчәләренә (затларга) әлеге карарның 1 пункты белән расланган акт нигезендә:

1) 2017 елның 31 декабренә кадәр муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын формалаштырырга һәм аларны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга;

2) муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын алып баруны һәм аларны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында актуаль хәлдә урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын актуаль хәлдә тоту, шулай ук үзгәрешләрне вакытында кертүне тәэмин итү, законнарга туры килми торган муниципаль норматив хокукый актларның үз көчләрен югалтуын тану максатларында эш башкару һәм документ әйләнеше өчен җаваплы бүлекчәләргә (затларга) әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән затларга, муниципаль норматив хокукый актларга (гаммәви мәгълүмат чараларында, суд актларында, контроль яки күзәтчелек органнарының җавап бирү актларында, хокукый экспертиза бәяләмәләрендә һәм башкаларда басылып чыгу турында) карата кергән көнендә яки, күрсәтелгән срокта тапшырылмаган очракта, киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча, мәгълүмат бирүне тәэмин итүне йөкләргә.

5. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына тәкъдим итәргә:

әлеге карарның 1 пункты белән расланган Нигезләмәгә таянып эшләргә һәм җирлекләрнең җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын алып бару тәртибе турында муниципаль норматив хокукый актларны кабул итәргә;

кабул ителгән муниципаль норматив хокукый актлар нигезендә муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын алып баруны оештырырга һәм аларны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы рәсми сайты җирлекләренең тиешле бүлекләренә урнаштыруны тәэмин итәргә.

6. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы Аппаратының оештыру бүлегенең баш белгеченә һәм юридик бүлегенең баш белгеченә (алар Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарыннан җыю һәм Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен муниципаль норматив хокукый актлар һәм алар турында мәгълүматлар җибәрү өчен җаваплы) җирлек дәрәҗәсендәге муниципаль норматив хокукый реестрларны алып баруны тәэмин итү максатларында күрсәтелгән җирле үзидарә органнары белән (килешенү буенча) хезмәттәшлекне оештырырга.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

8. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

9. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппаратына әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

10. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе И.Г. Вәлиев

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советының
2017 елның 29 маендагы
XIX-6 номерлы карары
белән расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын алып бару тәртибе турындагы**
**Нигезләмә**

1.Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын алып бару тәртибе турындагы Нигезләмә (алга таба – Нигезләмә, реестрлар, җирле үзидарә органнары тиңдәшле рәвештә) “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, “Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматка керү мөмкинлеген тәэмин итү хакында” 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, норматив хокукый базаны камилләштерү, җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән норматив хокукый актларны исәпкә алуны унификацияләү һәм системалаштыру, аларның эшчәнлеге турында мәгълүматның ачыклыгын тәэмин итү максатларында эшләнде.

1.2. Реестрлар бер үк вакытта (параллель рәвештә) муниципаль хокукый актларның гомуми реестрлары, эш башкару һәм документ әйләнеше бүлекчәләре һәм җирле үзидарә органының норматив һәм норматив булмаган характердагы (хокук куллану актлары) актларын исәпкә алу өчен хезмәткәрләр белән бер үк вакытта (параллель рәвештә) алып барыла һәм аларны тулысынча яки бер өлешендә алыштырмый. Реестрлар муниципаль норматив хокукый актларны теркәү өчен хезмәт итми.

1.3. Реестрлар түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү өчен хезмәт итә:

норматив характердагы муниципаль хокукый актларны исәпкә алу, алар турында мәгълүматлар, аларның законнарга туры килүен тикшереп тору;

коррупциягә каршы экспертизаныү үзвакытында үткәрелүен һәм муниципаль норматив хокукый актларны вакытында бастырып чыгаруны, законнарда билгеләнгән очракларда дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органнарына актлар һәм мәгълүматларны үз вакытында җибәрүне контрольдә

тоту ;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы, Башлыгы, Башкарма комитеты һәм башка җирле үзидарә органнары, аларның вазыйфаи затлары һәм аппаратлары эшчәнлеген оператив мәгълүмат бирү һәм белешмә белән тәэмин итү;

гражданнарның һәм юридик затларның, шул исәптән хуҗалык итүче субъектларның, иҗтимагый һәм башка кызыксынган оешмаларның, массакүләм мәгълүмат чаралары, контроль (күзәтчелек) органнарының һәм башкаларның норматив хокукый базасына керә алуын тәэмин итү.

1.4. Реестр – һәркем өчен мөмкин булган формада рәсмиләштерелгән һәм җирле үзидарә органының барлык муниципаль норматив хокукый актлары турында нигезләмәнең 2 бүлегендә билгеләнгән тәртип нигезендә мәгълүматлар базасы (махсус программа тәэминаты кулланмыйча мәгълүматны чагылдыра торган таблица форматында).

1.5. Җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын алып бару өчен вәкаләтле затлар-хокукый (юридик) бүлекчәләр (юристлар) яисә норма чыгару эше өчен җаваплы затлар, җирле үзидарә органнары аппаратлары.

1.6. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырыла торган реестрларның компьютер (цифрлы) версияләрен алып бару өчен нигезләмәнең 1.5 пунктында күрсәтелгән органнар (затлар) белән билгеләнгән тәртиптә үзара бәйләнештә торучы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының гомуми бүлеге башлыгы урынбасары (мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүмати куркынычсызлык буенча) җаваплы булып тора.

## 2. Реестрларны формалаштыру һәм алып бару

2.1. Реестрлар электрон рәвештә рус телендә алып барыла.

2.2. Реестрларга муниципаль норматив хокукый актлар турында мәгълүматлар кертелә:

басылып чыкканнары да, бастырылмаганнары да;

гамәлдә булганнары да һәм үз көчен югалтканнары да, башка актлар белән юкка чыгарылган яки үзгәртелгәннәре;

башка актларга үзгәрешләр кертү яки көчен югалтуны тану, башка актларның гамәлдә булу вакытын гамәлдән чыгару, туктату яки озайту турында.

2.3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы аппаратында алып барыла торган реестрларга (1 нче, 2 нче кушымталар) мәгълүматлар кертелә:

җирле референдумда кабул ителгән хокукый актлар рәвешендә рәсмиләштерелгән карарлар турында;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы кабул иткән карарлар турында.

2.4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы

Башлыгының муниципаль норматив хокукый актлар реестрына (3 нче кушымта) мәгълүматлар кертелә:

норматив характердагы карарлар турында;

норматив характерда булган аерым нигезләмәләрне үз эченә алган күрсәтмәләр турында.

2.5. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты аппаратында (4 нче кушымта) алып барыла торган реестрга түбәндәге мәгълүматлар кертелә:

норматив характердагы карарлар турында;

норматив характерда булган аерым нигезләмәләрне үз эченә алган күрсәтмәләр турында.

2.6. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының башка җирле үзидарә органнары аппаратларында алып барыла торган реестрларга Нигезләмәнең 2.3-2.5 пунктларында (5 нче кушымта) күрсәтелмәгән мәгълүматлар кертелә:

норматив характерда булган аерым нигезләмәләрне үз эченә алган күрсәтмәләр турында;

норматив характерда булган (норматив характерда булган аерым нигезләмәләрне үз эченә алган) боерыклар турында.

2.7. Реестрларга түбәндәге мәгълүматлар кертелә:

хокукый акт төре (хокукый актларның һәр төре буенча аерым исемлек алып барырга киңәш ителә);

кабул итү көне;

теркәү номеры (муниципаль хокукый актларның тиешле реестры белән билгеләнгән, эш башкару һәм документлар әйләнеше бүлекчәсе тарафыннан билгеләнә);

аталышы (булган сурәттә).

2.8. Реестрларга муниципаль норматив хокукый актлар турында түбәндәге өстәмә белешмәләр кертелергә тиеш:

басылып чыгу турында (халыкка җиткерү);

үзгәрешләр кертү (көчне югалту, юкка чыгару), суд тарафыннан гамәлдә түгел дип тану турында.

2.8.1. Реестрларга муниципаль норматив хокукый актлар турында башка өстәмә мәгълүмат кертелергә мөмкин.

2.9. Муниципаль норматив хокукый актлар турындагы мәгълүматлар актларны кабул итү (бастырып чыгару) датасы нигезендә хронологик тәртиптә реестрларда урнаштырыла.

2.10. Җирле үзидарә органнары җитәкчеләре эш башкару һәм документлар әйләнеше өчен җаваплы бүлекчәләргә (затларга) йөклиләр, Нигезләмәнең 1.5 пунктында күрсәтелгән затларга яки бүлекчәләргә Нигезләмәнең 2.7, 2.8 пунктларында каралган мәгълүматны бирүне тәэмин итәргә, кергән (формалашкан) көнне яисә күрсәтелгән срокта тапшыра алмаган очракта, киләсе өч эш көне эчендә.

Реестрларга 2017 елда кабул ителгән муниципаль норматив хокукый актлардан башлап, яңа кабул ителгән муниципаль норматив хокукый

актларның (яисә хокукый базаны мониторинглау нәтиҗәсендә ачыкланган актларның) текстлары кушымта итеп бирелә.

2.11. Нигезләмәнең 1.5 пунктында күрсәтелгән бүлекчәләр яки затлар Нигезләмәнең 2.10 пунктында күрсәтелгән мәгълүматны эшкәртә һәм реестрларга кертә, шулай ук муниципаль норматив хокукый актларның беркетелгән текстлары белән бергә түбәндәге биш эш көне дәвамында Нигезләмәнең 1.6 пункты белән билгеләнгән бүлекчәләргә (җаваплы затларга) җибәрелә.

Үзгәрешләр кертүче актлар кергәндә җиде эш көне дәвамында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында үзгәртелә торган муниципаль норматив хокукый актларның актуаль редакцияләрен урнаштыру өчен төзелә һәм җибәрелә.

2.12. Нигезләмәнең 1.6 пунктында билгеләнгән бүлекчәләр (затлар) реестрның актуаль редакциясен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы сайтында һәм Нигезләмәнең 2.10 пунктындагы икенче абзацында, Нигезләмәнең 2.11 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән актлар текстларын кергән көннән алып өч эш көне эчендә урнаштыралар.

Җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы рәсми сайты турында мәгълүмат булган бүлекләрдә реестрлар тиешле җирле үзидарә органнары муниципаль норматив хокукый актлары исемлегенең беренче файллары буларак урнаштырыла. Муниципаль норматив хокукый актларның текстлары Нигезләмәнең 2.9 пунктында билгеләнгән реестрларда алар турында мәгълүмат урнаштыру тәртибе белән килешенгән тәртиптә урнаштырыла.

Үзгәртелә торган муниципаль норматив хокукый актларның актуаль редакцияләре аларда үзгәрешләр кертә торган актлар артына урнаштырыла.

2.13. 2.10 пунктының икенче абзацында, 2.11 пунктның икенче абзацында күрсәтелгән муниципаль норматив хокукый актларның текстлары, дәүләт серен (конфиденциаль характердагы башка мәгълүматларны) тәшкил иткән очракта, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш түгел. Мондый актлар турындагы мәгълүмат аларның эчтәлеген ачарга рөхсәт итмәгән өлешендәге реестрларга кертелергә мөмкин.

## 3. Реестрлардагы мәгълүмат бирү тәртибе һәм шартлары. Мәгълүмати хезмәттәшлекнең башка мәсьәләләре

3.1. Реестрлардагы мәгълүмат Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырыла торган һәркем өчен мөмкин. Аны электрон образлар (файллар) рәвешендә алу кызыксынган кешеләр өчен чикләнелми.

3.2. Законнарда каралган очракларда вәкаләтле органнарга реестрлардагы һәм бирелергә тиешле мәгълүматны бирү (тапшыру) тиешле норматив хокукый актлар белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

3.3. “Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә

органнарына муниципаль районга керүче җирлекләрдән мәгълүмат җыю буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” 2015 елның 3 ноябрендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә җаваплы затлар күрсәтелгән мәгълүматларны җыю өчен җирлекләрдә тиешле реестрларны алып баруны тәэмин итү максатларында муниципаль район составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән үзара бәйләнешне (килешенү буенча) оештыралар.

## 4. Реестрларны алып бару тәртибен бозган өчен җаваплылык

4.1. Нигезләмәнең 1.5, 1.6, 2.10 пунктларында күрсәтелгән җитәкчеләр һәм башка вәкаләтле затлар нигезләмә белән билгеләнгән реестрларны алып бару тәртибен бозган өчен дисциплинар җаваплылыкка тартыла (яисә башка билгеләнгән җаваплылык төренә).

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе
муниципаль районы җирле үзидарә
органнарында муниципаль норматив
хокукый актлар реестрларын алып бару
тәртибе турындагы Нигезләмәгә
кушымта №1
*(үрнәк рәвеш)*

**Татарстан Республикасы**
**Балык Бистәсе муниципаль район Советының**
**муниципаль норматив хокукый актлары (карарлары)**
**РЕЕСТРЫ**

| №№ п/п | Кабул итү датасы | Акт №ы | Актның аталышы | Рәсми басылу чыганагы һәм датасы | Өстәмә мәгълүматлар * | Искәрмәләр |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **200_ ел** | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| **20__ ел** | | | | | | |
| | | | | | | |
| **20__ ел** | | | | | | |
| | | | | | | |

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе
муниципаль районы җирле үзидарә
органнарында муниципаль норматив

хокукый актлар реестрларын алып бару
тәртибе турындагы Нигезләмәгә
кушымта №2
*(үрнәк рәвеш)*

**Татарстан Республикасы**
**Балык Бистәсе муниципаль районында**
**җирле референдумнарда кабул ителгән**
**муниципаль норматив хокукый актлар рәвешендә**
**рәсмиләштерелгән карарлар**
**РЕЕСТРЫ**

| №№ п/п | Кабул итү датасы | Акт №ы | Актның аталышы | Рәсми басылу чыганагы һәм датасы | Өстәмә мәгълүматлар* | Искәрмәләр |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **200_ ел** | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| **20__ ел** | | | | | | |
| | | | | | | |
| **20__ ел** | | | | | | |
| | | | | | | |

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе
муниципаль районы җирле үзидарә

органнарында муниципаль норматив
хокукый актлар реестрларын алып бару
тәртибе турындагы Нигезләмәгә
кушымта №3
***(үрнәк рәвеш)***

**Татарстан Республикасы**
**Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгының**
**муниципаль норматив хокукый актлары**
**РЕЕСТРЫ**

| №№ п/п | Кабул итү датасы | Акт №ы | Актның аталышы | Рәсми басылу чыганагы һәм датасы | Өстәмә мәгълүматлар * | Искәрмәләр |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **20__ ел** | | | | | | |
| **Карарлар** | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| **Күрсәтмәләр** | | | | | | |
| | | | | | | |
| **20__ ел** | | | | | | |
| **Карарлар** | | | | | | |
| | | | | | | |
| **Күрсәтмәләр** | | | | | | |
| | | | | | | |
| **20__ ел** | | | | | | |
| **Карарлар** | | | | | | |
| | | | | | | |
| **Күрсәтмәләр** | | | | | | |
| | | | | | | |

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе
муниципаль районы җирле үзидарә
органнарында муниципаль норматив
хокукый актлар реестрларын алып бару

тәртибе турындагы Нигезләмәгә
кушымта №4
***(үрнәк рәвеш)***

**Татарстан Республикасы**
**Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының**
**муниципаль норматив хокукый актлар**
**РЕЕСТРЫ**

| №№ п/п | Кабул итү датасы | Акт №ы | Актның аталышы | Рәсми басылу чыганагы һәм датасы | Өстәмә мәгълүматлар* | Искәрмәләр |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **20__ ел** | | | | | | |
| **Карарлар** | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| **Күрсәтмәләр** | | | | | | |
| | | | | | | |
| **20__ ел** | | | | | | |
| **Карарлар** | | | | | | |
| | | | | | | |
| **Күрсәтмәләр** | | | | | | |
| | | | | | | |
| **20__ ел** | | | | | | |
| **Карарлар** | | | | | | |
| | | | | | | |
| **Күрсәтмәләр** | | | | | | |
| | | | | | | |

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе
муниципаль районы җирле үзидарә
органнарында муниципаль норматив
хокукый актлар реестрларын алып бару
тәртибе турындагы Нигезләмәгә

кушымта №5
*(үрнәк рәвеш– Палаталар өчен)*

**Татарстан Республикасы**
**Балык Бистәсе муниципаль районының**
**________________________ муниципаль**
**норматив хокукый актлар**
**РЕЕСТРЫ**

| №№ п/п | Кабул итү датасы | Акт №ы | Актның аталышы | Рәсми басылу чыганагы һәм датасы | Өстәмә мәгълүматлар* | Искәрмәләр |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **20__ ел** | | | | | | |
| **Күрсәтмәләр** | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| **Боерыклар** | | | | | | |
| | | | | | | |
| **20__ ел** | | | | | | |
| **Күрсәтмәләр** | | | | | | |
| | | | | | | |
| **Боерыклар** | | | | | | |
| | | | | | | |
| **20__ ел** | | | | | | |
| **Күрсәтмәләр** | | | | | | |
| | | | | | | |
| **Боерыклар** | | | | | | |
| | | | | | | |

* “Өстәмә мәгълүматлар” графасына үзгәрешләр кертү хакында, муниципаль норматив хокукый актларның үз көчләрен югалтуын тану турында, прокурор илтифаты актлары, суд актлары, аларга карата чыгарылган башка контроль-күзәтчелек органнары актлары турындагы мәгълүматлар кертелә.